ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 9 марты** **Чистай шәһәре** **№ 124**

Балигъ булган дип танылган
суд тарафыннан хокуктан файдалануга
сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте
чикләнгән дип танылган гражданнарга
карата опека һәм попечительлек өлкәсендә
дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ
регламентларының үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2020 елның 13 ноябрендәге «Кредит оешмасында счеттагы акчаларны суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә чикләнгән эшкә сәләтсез затка карата ябу, төшерү, күчерү, тоту өчен алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 1951 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2020 елның 13 ноябрендәге «Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган зат мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 1954 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2020 елның 13 ноябрендәге «Суд тарафыннан хокукка сәләтсез яисә хокукка сәләте чикләнгән дип танылган затка ия булган күчемсез мөлкәтне читләштерү (шул исәптән алмаштыру яисә бүләк итү буенча) буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 1955 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2020 елның 13 ноябрендәге «Суд тарафыннан эшкә сәләтсез яки чикләнгән эшкә сәләтсез дип танылган затка, наемга (арендага), түләүсез файдалануга милек тапшыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 1958 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 2020 елның 23 декабрендәге 09-01/15903 номерлы, 2020 елның 23 декабрендәге 09-01/15904 номерлы, 2020 елның 30 декабрендәге 09-01/16422 номерлы, 2020 елның 30 декабрендәге 09-01/16440 номерлы хатлары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан балигъ булган гражданнарга карата суд тарафыннан хокуктан

файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын үз көчен югалткан дип танырга:
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 17 декабрендәге 1030 номерлы карары белән расланган опекунга яисә попечительгә тәрбиягә алучының саклык счетыннан файдаланууга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты;
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 17 декабрендәге 1030 номерлы карары белән расланган тәрбиядәге бала мәнфәгатьләрендә гомерлек рента шартнамәсе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты;
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 17 декабрендәге 1030 номерлы карары белән расланган подопечныйлар мөлкәте белән алыш-бирешләр кылуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты;
- Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 17 декабрендәге 1030 номерлы карары белән расланган бала карамагындагы торак тапшыруга опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты.

2. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә (Сударкина С.А.) әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә һәм әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Л.Х. Кашаповага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов